СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӨҢШЕҢӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
23 июня 2020 г.

КАРАР
№ 134

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул иткән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча «Хезмәт» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга.

Шеңшеңәр авыл җирлеге
башлыгы

Р. Х. Салихҗанов

М.У.